ГОРОДСКОЙ СОВЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
ШӘҺӘР СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

21 февраль, 2018 ел № 23/6

2017 елда Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге бюджеты үтәлеше турында хисап проекты буенча җәмәгать тыңлаулары хакында

2003 елның 06 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 131-ФЗ санлы Федераль законның 28 маддәсенә, Татарстан Республикасы Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Уставының 19, 28 маддәләренә, Шәһәр Советының 2008 елның 25 сентябрендәге 34/8 санлы Карары белән расланган гавами тыңлауларны оештыру һәм үткәрү тәртибе турында Нигезнамәгә таянып,

Шәһәр Советы

КАРАР бирде:

1. 2017 елда Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге бюджеты үтәлеше турында хисап проекты буенча гавами тыңлауларны үткәрү көнен 2018 елның 12 мартына, үткәрү вакытын 14:00 сәгатькә тәгаенләргә, җәмәгать тыңлауларын үткәрү урыны итеп Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты бинасын (Х.Туфан проспекты, 23 йорт), 400 залны билгеләргә.
2. 2017 елда Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге бюджеты үтәлеше турында хисап проекты буенча җәмәгать тыңлауларын үткәрү буенча комиссия составын кушымтада каралганча расларга.
3. Әлеге Карар үтәлешен тикшереп торуны Шәһәр Советының социаль-икътисадый үсеш мәсьәләләре һәм бюджет буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Шәһәр Хакиме Н.Г. Мәһдиев

Шәһәр Советының 23/6 Карарына
кушымта
21 февраль, 2018 ел

2017 елда Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге бюджеты үтәлеше турында хисап проекты буенча җәмәгать тыңлаулары үткәрү комиссиясе составы

| | |
|---|---|
| Сәгыйдуллина Ирина Алексеевна | – комиссия рәисе, Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары, финанс идарәсе башлыгы вазыйфаларын башкаручы; |

комиссия әгъзалары:

| | |
|---|---|
| Әхмәтҗанов Ленар Илдар улы | – Башкарма комитетның хокук идарәсе башлыгы; |
| Галиева Ләйсән Ринат кызы | – Башкарма комитетның финанс идарәсе бюджет сәясәте бүлеге башлыгы; |
| Хәбибрахманова Эльвира Марс кызы | – Башкарма комитетның финанс идарәсе бюджет бүлегенең баш белгече; |
| Хамаева Гөлназ Гарифулла кызы | – Башкарма комитетның финанс идарәсе башлыгы урынбасары, бюджет бүлеге башлыгы. |